ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2026 п.г.т.Алексеевское № 134

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма**
**комитетының 25.07.2018 ел, № 205**
**«Алексеевск муниципаль районы чикләрендәге**
**торак пунктлар арасындагы территориядә**
**гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында**
**пассажирлар йөртү һәм багаж ташу**
**Кагыйдәләрен раслау турында» карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына туры китереп

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Алексеевск муниципаль районы чикләрендәге торак пунктлар арасындагы территориядә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу Кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 25 июлендәге 205 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 бүлекнең 18 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 13.1 пунктның 2 абзацында «Пассажирның йөртү түләве буенча өстенлекләре булган баланың яшен раслый торган документы (туу турында таныклыгы яисә бала туу турында язулы ата-ана паспорты) булырга тиеш, ул юл йөрү өчен түләүне тикшереп торучы затларның беренче таләбе буенча мәҗбүри рәвештә күрсәтелә;» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 13.2 пунктның 4 абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 14

февралендәге 112 номерлы карарының II бүлеге нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча : http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Е. Н.Мельниковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**